РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Малосалтыковского**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ул. Б. Урманче, 9 с. Малые Салтыки, 422812
тел. (8277)36-2-18, факс: (8277) 36-2-18
ОКПО 9405059 ОГРН 1061672018033
ИНН/КПП 1622004757/1162201001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Кече Салтык**
**авыл җирлеге**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Б.Урманче урамы, 9,Кече Салтык авылы, 422812,
тел. (8277)36-2-18, факс: (8277) 36-2-18
ОКПО 9405059 ОГРН 1061672018033
ИНН/КПП 1622004757/1162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**«30» гыйнвар 2020 ел** **№ 3**

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында” Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлегендә № 1 кушымта һәм № 2 кушымта нигезендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә 6124,86 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында" 2019 ел, 11 апрель, 27 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Салтык авылы, Бакый Урманчы ур., 9;
- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Мәрәтхуҗа авылы, Вахитов ур., 9; һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2020 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Кече Салтык авыл җирлеге**
**башкарма комитеты җитәкчесе** **А.Г.Җиһаншин**

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына кушымта № 1
30.01.2020 ел № 3

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлегендә 2020 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| **Хезмәтләрнең исеме** | **Хезмәтләрнең бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2.Кәфенлекне, җирләү өчен кирәкле башка предметларны тәкъдим итү һәм китерү | 3670,18 |
| 3.Зиратка үлгән кешенең мәетен китерү | 522,27 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм җирләү) | 1932,41 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына кушымта № 2
30.01.2020 ел № 3

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлегендә 2020 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| **Хезмәтләрнең исеме** | **Хезмәтләрнең бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Тәнне каплау | 188,35 |
| 3. Җирләү җыелмасы- Кәфенлек, такта комплекты, җирләү өчен кирәкле башка предметларны тәкъдим итү һәм китерү | 3481,83 |
| 4. Зиратка үлгән кешенең мәетен китерү | 522,27 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм җирләү) | 1932,41 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |